| | |
|---|---|
| **ГЛАВА<br>СТАРОШАЙМУРЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ИСКЕ ШӘЙМОРЗА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

с.Старое Шаймурзино

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 24 ноябре № 23

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Иске Шәйморза
авыл җирлегенең Иске Шәйморза торак
пунктында үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә белән расланган Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының 07.10.2019 ел, № 51/1 карары (15.11.2019 ел, №53/5 редакциясендә) КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлегенең Иске Шәйморза торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 6 декабренә 13:30 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Шәйморза авылы, Ленин урамы, 61 йорт, Иске Шәйморза мәдәният йорты.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Иске Шәйморза авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә акча кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару белән килешәсезме?:

-Иске Шәйморза авылынын Ленин, Крупская, Пионер, СХТ, Татарстан, А.Ш.Абдреев урамындагы юлларга вак таш салу;

-Иске Шәйморза авылы паркын төзекләндерү;

-Иске Шәйморза авылы зиратында ТКО өчен контейнерлар төзү;

-Иске Шаймурзино авылында агач кисү, куакларны кисү;

-Иске Шаймурзино авылындагы территорияне рөхсәтсез чүп-чардан чистарту

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлегенең Иске Шәйморза торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»2021 елның 18 ноябрендәге 22 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Иске Шәйморза авыл җирлеге башлыгы: И.Д.Мөхитова